**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 63-8 «25» июнь 2021 ел

2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына физик затлар керемнәренә салымнан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына күчерелә торган өстәмә норматив белән бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотация алмаштыруны килештерү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 138 статьясындагы 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына физик затлар керемнәренә салымнан 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына күчерелгән өстәмә норматив белән муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотация алмаштыруны килештерергә.

2. Әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru..

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин